СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы карары**

**« 25 » ноябрь 2024 ел №108**

**"Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында" 04.06.2024 № 97 Яңасала авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (01.07.2024№ 98 үзгәрешләр белән)**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында кодекс, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең хезмәт хакы бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 05 сентябрендәге 731 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге уставы нигезендә, Яңасала авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында» Яңасала авыл җирлеге Советының 04.06.2024 №97 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1) муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү турындагы нигезләмәнең 2 пунктын (1 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның хезмәте өчен түләү акчалата түләү рәвешендә башкарыла.

| Вазыйфа исеме | Акчалата түләү күләме, сум |
|---|---|
| Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башлыгы | 19 173 |

2) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга хезмәт өчен түләү турындагы нигезләмәнең 3 пунктында (2 нче кушымта) «13 323 сум» сүзләрен «13 990 сум» сүзләренә алмаштырырга.

3) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында нигезләмәнең 3 пунктын (3 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлегенең айлык тариф ставкалары күләмнәре түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә::

| Бердәм тариф челтәренең түләү разряды | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 21 200,0 |
| 2 | 1,0114 | 21 442,0 |
| 3 | 1,0233 | 21 694,0 |
| 4 | 1,0346 | 21 934,0 |
| 5 | 1,0473 | 22 203,0 |

4.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге баш хисапчысының хезмәте өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын (4 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
Баш хисапчының вазыйфаи оклады түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары |
|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр |
| Баш хисапчы | 25 700 сум |

2. Әлеге карарның 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында Авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл җирлеге башлыгы А.И.Сафин